**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 10 февралендәге 311 номерлы карары**

## Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләрнең хезмәткәрләренә хезмәте өчен түләү турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

2025 елның 1 гыйнварыннан хезмәт өчен түләүнең минималь күләме арту белән бәйле рәвештә һәм хезмәт законнары таләпләрен үтәү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 18 гыйнварындагы 100 номерлы «Учреждениеләргә үзәкләштерелгән бухгалтерлык, хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтүне гамәлгә ашыра торган муниципаль учреждениеләр, оештыру һәм финанс эшчәнлеген тәэмин итә торган хезмәтләрнең хезмәткәрләренә хезмәте өчен түләү турында»гы карарның 2 номерлы кушымтадагы «Хезмәт хакының айлык ставкасы, аны билгеләү тәртибе һәм шартлары» дигән II бүлекнең 1 нче таблицасын түбәндәге редакциядә биреп, үзгәреш кертергә:

«*1 нче таблица*

### Эшчеләрнең айлык хезмәт хакы ставкалары

| № т/б | Эшче һөнәрләрнең аталышы | Хезмәт хакының айлык ставкасы, сумнарда | Казан шәһәрендә үзәкләштерелгән бухгалтерлык һәм хуҗалык-эксплуатация хезмәте күрсәтә торган учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче автомобиль йөртүчеләр өчен хезмәт хакының айлык ставкасына арттыру коэффициенты |
|---|---|---|---|
| 1 | Җыештыручы | 22 440 | - |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2 | Каравылчы | 22 440 | - |
| 3 | Автомобиль йөртүче | 22 440 | 1,27 |
| 4 | Вахтер | 22 440 | - |
| 5 | Хуҗалык өчен җаваплы хезмәткәр | 22 440 | - |
| 6 | Биналарга хезмәт күрсәтүче эшче | 22 440 | - |
| 7 | Урам себерүче | 22 440 | -» |

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Р.Сәгыйтовага йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**